ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«3» «март» 2021 ел №132

**2021 елда югары җитештерү күрсәткечләренә ирешкән өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы терлекчелек предприятиеләренең алдынгы хезмәткәрләрен бүләкләү турында Нигезләмәне раслау хакында**

Арча муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең терлекчелек продукциясе җитештерү күләмен алга таба арттыру, авыл хуҗалыгы терлекләренең продуктивлыгын һәм баш санын үстерү, авыл хуҗалыгы оешмалары хезмәткәрләрен югары күрсәткечләргә ирешүгә кызыксындыру эшенә нәтиҗә ясау максатыннан, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Раслаарга:

1.1. 2021 елда югары җитештерү күрсәткечләренә ирешкән өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең алдынгы хезмәткәрләрен бүләкләү турында Нигезләмәне (1нче кушымта).

1.2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең алдынгы хезмәткәрләрен билгеләү буенча район комиссиясе составын (2нче кушымта).

2. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. «Татмедиа» ААҖ филиалы «Арча газетасы редакциясе»нә язгы кыр эшләренең барышын һәм комиссия материалларын даими рәвештә киң яктыртырга. Алдынгы хезмәтне пропагандалау һәм хезмәткәрләрне рухи яктан кызыксындыру максатыннан «Мактау тактасы» рубрикасы оештырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http: pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http: arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р. Мөхәрәмов

*Татарстан Республикасы*
*Арча муниципаль районы*
*Башкарма комитетының*
*03.03.2021* *ел, №* *132*
*карарына 1нче кушымта*

**2021 елда югары җитештерү күрсәткечләренә ирешкән өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы терлекчелек предприятиеләренең алдынгы хезмәткәрләрен бүләкләү турында**
**Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Арча муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең терлекчелек продукциясе күләмнәрен арттыру, авыл хуҗалыгы терлекләренең продуктивлыгын һәм баш санын үстерү, авыл хуҗалыгы оешмалары хезмәткәрләрен югары күрсәткечләргә ирешүгә кызыксындыру эшенә нәтиҗә ясау максатынан эшләнде.

1.2. Предприятиеләр буенча да, тулаем район буенча да хисап аенда иң югары күрсәткечләргә ирешкән Арча муниципаль районы авыл хуҗалыгы берләшмәләренең терлекчелек тармагы хезмәткәрләре бүләкләнә. Нәтиҗәләр 2021 елның февраленнән башлап, һәр айның 25 еннән соң ясала.

1.3. Бүләкләү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы терлекчелек предприятиеләренең алдынгы хезмәткәрләрен билгеләү буенча район комиссиясе (алга таба - комиссия) терлекчелек тармагында җитештерү алдынгыларын билгели.

1.4. Җитештерү алдынгыларын билгеләгәндә, комиссия тарафыннан дәгъвачыларның җитештерү күрсәткечләре яисә аларның җитештерү эшчәнлеге нәтиҗәләренә ирешүдә өлеше исәпкә алына.

1.5. Җиңүчеләрне бүләкләү район авыл хуҗалыгы оешмаларының терлекчелек фермаларына барып үткәрелә.

1.6. Оештыручылар - Арча муниципаль районы башкарма комитеты һәм Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе.

1.7. Финанслау Арча муниципаль районы бюджеты хисабына гамәлгә ашырыла. Барлыгы 51 кеше бүләкләнә, алдынгы терлекчеләрне бүләкләүгә 102 мең сум бирелә.

## 2. Максат һәм бурычлар

2.1. Арча муниципаль районында терлекчелек тармагы продукциясен җитештерүдә иң югары күрсәткечләргә ирешкән алдынгыларны ачыклау.

2.2. Авыл хуҗалыгы оешмалары хезмәткәрләрен югары күрсәткечләргә ирешүгә кызыксындыру.

2.3. Терлекчелек тармагы алдынгыларын рухи һәм матди кызыксындыру, хезмәт эшчәнлегендә югары күрсәткечләргә кызыксындыру.

2.4. Яшь хезмәткәрләрне җәлеп итү өчен авыл хуҗалыгы һөнәрләренең абруен күтәрү.

## 3. Терлекчелек тармагы алдынгыларын бүләкләү тәртибе

3.1. Бүләкләү өчен алдынгыларның җитештерү күрсәткечләре, авыл хуҗалыгы оешмасында эш стажы, оешмалар җитәкчеләренең бүләкләү турында үтенечнамәләре исәпкә алына.

3.2. Хисап аенда иң күп сөт сауган машина белән сыер савучы операторлар, бозаулардан иң югары тәүлеклек артым алган бозау караучылар яисә терлекчеләр, шулай ук яшь терлекләрнең буазлыгын һәм баш санын тикшерү нәтиҗәләре буенча мөгезле эре терлек башын арттырган ветеринария табиблары һәм технологлар бүләкләнә.

3.3. Алдынгыларның барысы да 2000 сумлык акчалата премия һәм Арча муниципаль районы башлыгының рәхмәт хаты белән бүләкләнә.

*Татарстан Республикасы*
*Арча муниципаль районы*
*Башкарма комитетының*
*03.03.2021 ел,№ 132*
*карарына 2 нче кушымта*

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы терлекчелек предприятиеләренең алдынгы хезмәткәрләрен билгеләү буенча район комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Гатиятов Р.М. | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районындагы идарәсе башлыгы - комиссия рәисе (килешү буенча). |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Галимуллина Г.Х. | Арча муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм финанслар бүлеге башлыгы; |
| Абдуллин Л.И. | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районындагы идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча); |
| Абдуллин М.Р. | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районындагы идарәсенең ФЭО башлыгы (килешү буенча); |
| Хәйретдинов Р.Р. | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районындагы идарәсенең ПМО консультанты (килешү буенча); |
| Фәйзрахманов Р.А. | «Арча РДВБ» ДБУ башлыгы (килешү буенча); |
| Зарифуллина З.М. | Арча муниципаль районының селекция-нәсел хезмәте башлыгы (килешү буенча). |